| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Лешев-Тамакского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Ләшәү Тамак авыл җирлеге<br>советы |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 2020 ел, 24 сентябрь | № 7 |

Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының» Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бердәм шәхси башкарма орган буларак яллаучы (эш бирүче) вәкиленә коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен кире кайтарылмый торган нигездә катнашу өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 22 августындагы 11 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 1 өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Гамәлдән чыгарырга:

Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бердәм шәхси башкарма орган буларак идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) яисә аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керүе өчен кире кайтарылмый торган нигездә катнашу рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 22 августындагы 11 номерлы карарны.

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрне коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) идарәсендә шәхси бердәм башкарма орган сыйфатында кире кайтарылмый торган нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 маенда 19 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» карарны.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO TATARSTAN.RU) һәм «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Советы Рәисе И.З.Хабибуллин